ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.10.2020 ел Баулы шәһәре №191

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре җитәкчеләре, белгечләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 178 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кулланылмаган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре җитәкчеләре, белгечләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 178 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

беренче пунктта «, кушымта нигезендә.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа 2 пункт өстәргә:

«2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм бухгалтерлык исәбе бүлекләре җитәкчеләренең, белгечләренең

вазыйфаи окладлары күләмнәрен, шулай ук айлык һәм башка түләүләр күләмнәрен арттыру ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш дип билгеләргә.»;

2 пунктны 3 пункт дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 4 сентябрендәге
178 номерлы карарына
кушымта

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булган муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренең, үзәкләштерелгән бухгалтерияләр һәм бухгалтерлык исәбе бүлекләренең вазыйфаи окладлары

| Җитәкче һәм белгеч вазифасы | Вазифаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 24 411 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 22 145 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 22 145 |
| Бүлек җитәкчесе | 18 231 | 18 231 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15 759 | 15 759 |
| Бухгалтер | 14 420 | 14 420 |

».

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров